| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МӨЭМИН-КАРАТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

Мөэмин-Каратай ав

2025 елның 23 июне № 14

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 15 октябрендәге 7 номерлы «Җир салымы турында» (02.11.2023 №43, 06.06.2024 №11) карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 394 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 15 октябрендәге 7 номерлы «Җир салымы турында» (02.11.2023 №43, 06.06.2024 №11) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 0,3% торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,3% (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге абзацта индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш, һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләре;

«- 0,25% шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләре, әлеге абзацта күрсәтелгән һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш;».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мөэмин-Каратай авылы, Механизаторлар ур., 31Б йорт адресы буенча урнашкан җирлекнең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үз йогынтысын 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Ә.А.Ханнанова